**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**

**Сәвәләй авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 21** **24.07.2026**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2026 елның 29 декабрендәге 20 номерлы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү турындаТатарстан Республикасы**

«Конкуренцияне яклау турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 577-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Советына таянып

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 29 декабрендәге 20 номерлы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына (Зәй муниципаль районынын 20.04.2021 № 27 номерлы, 10.03.2022 №56, 06.12.2022, № 82 номерлы, 28.02.2023 № 97 номерлы, 22.10.2024 № 145 номерлы, 2025 елның 18 июнендәге 171 номерлы Сәвәләй авыл җирлеге Советының түбәндәге үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.13. Әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктының икенче абзацында билгеләнгән очракта, аукционда җиңүче яисә аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган зат белән сату-алу шартнамәсе төзү аукцион йомгаклары турында беркетмәнең рәсми сайтында урнаштырылган көннән алып ун көннән дә иртәрәк булмаган вакытта һәм егерме көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. Муниципаль мөлкәт гавами сервитут һәм (яисә) 178-ФЗ номерлы Федераль законда һәм (яисә) башка федераль законнарда каралган чикләүләр белән йөкләнгән очракта, аукционда төзелә торган мондый мөлкәтне сату-алу шартнамәсенең мөһим шарты сатып алучының күрсәтелгән йөкләмә шартларын үтәү бурычы булып тора.”;

1.2. 6.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.12. Сату-алу шартнамәсен гавами тәкъдим юлы белән сату-алу шартнамәсен төзү, мөлкәтне сату йомгаклары турындагы беркетмәнең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында гавами

тәкъдим белән урнаштырылган көннән алып ун көннән дә соңга калмыйча һәм егерме көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.».

2.«Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) да, җирлекнең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында әлеге карарны бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегенә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Сәвәләй авыл җирлеге башлыгы** **С.К.Маклаков**